**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Мортыштамак авыл җирлеге Колмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 27 октябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

« 1. Колмәт торак пунктында электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән электр челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка мәйданчыкларны тышкы яктырту (яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, кабельне, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

2. Колмәт торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (таш сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Җәйге чорда (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) торак пункт территориясен төзекләндерү; бензин чапкычлары, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу;

4. Традицион күмелгән урыннарны ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (Колмәт торак пунктында зират территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру, сызу, Колмәт авылы зираты территориясендә югары буйлы агачларны кисү (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче — Һадиуллин И.Н.